| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.02.2020 г.Казань № 80

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 3 мартында 6538 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 19.07.2016 № 412, 08.06.2017 № 348, 25.01.2018 № 60, 07.05.2018 № 348, 18.09.2018 № 885, 02.07.2019 № 509, 14.11.2019 № 1016 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 7 февралендәге 80 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1.4.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренә (алга таба – КФҮ) һәм (яки) КФҮнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.»;

1.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 178-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, №29, 3699 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, №14, 1257 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары (алга таба – 512 номерлы карар)

(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, №34, 3374 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджетка карамаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №40, 5559 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 елның 21 июнендәге 539 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 13.07.2012, №51, 1733 статья);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 635 номерлы Нигезләмә)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, №68, 2080 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2 бүлектә:

2.2 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районы яисә шәһәр округының социаль яклау идарәсе (бүлеге)»;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында хәбәр гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул (почта адресы буенча язма формада, смс-хәбәр итеп, электрон почта белән) җибәрелә»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм әлеге Регламентның 1, 2, $2^1$ кушымталарына ярашлы форма буенча гариза бирүченең гаилә составы, керемнәре, милек хокукында гариза бирүченеке булган мөлкәт турында белешмәләр күрсәтелгән анкета.»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә), КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.»;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

«Гариза бирүчеләр гаризаны һәм документларның күчермәләрен КФҮ аша яки КФҮнең читтән торып эшләү урыны аша бирә ала.»;

2.6 пункттагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге белешмәләр алына:

гариза бирүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында (халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте учреждениеләрендә);

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбия кылучы, эшкә сәләтле эшләми торган затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырылучы материаль тәэмин итү буенча түләүләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында (Россия Оборона министрлыгында);

пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында);

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында (социаль яклау органнарында);

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында (социаль яклау органнарында);

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

гаиләне дәүләт теркәвенә алу турында (ГХАТ органнарында);

гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала караган өчен акча алуы турында (җирле үзидарә органнарында);

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында (җирле үзидарә органнарында);

гариза бирүчене ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яисә ата-ана хокукында чикләү турында (җирле үзидарә органнарында);

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарында);

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәте турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында (җирле үзидарә органнарында);

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында (вәкаләтле органнарда).

Әлеге белешмәләр гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге« графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

дәүләт хезмәтеннән файдаланучының гаилә составы, керемнәре һәм милек хокукында аның (аның гаиләсенең) милеге турында тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүматларны бирүе;

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә аның законлы вәкиленең, яисә гариза бирүче тарафыннан ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүе;

гаиләнең (гражданинның) мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсе гаиләнең (гражданинның) мөлкәт белән тәэмин ителүенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы кушымтасында билгеләнгән дәрәҗәсеннән артык булса, 18 яшенә кадәрге биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән тыш;

гражданинның тулы дәүләт тәэминатында булуы;

гариза бирүченең социаль адаптация һәм (яки) социаль контракт программасын имзаламавы»;

2.15 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

икенче, уникенче һәм унбишенче абзацларда «Үзәк бүлеге» сүзләрен «Идарә (бүлек)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электрон рәвештәге гаризаны КФҮ аша, КФҮнең ерактан торып эшләү урыны аша тапшыру мөмкинлеге;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлык сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урыныннан алынырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

Гариза бирүче КФҮ, КФҮ читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча Идарәгә (бүлеккә) тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарәнең (бүлекнең) һәм КФҮ үзара хезмәттәшлек итү тәртибе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән КФҮ арасында төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – КФҮ эш регламенты белән»;

3 бүлектә:

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарәдә (бүлектә) дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада, белешмәләр тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Татарстан Республикасында 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, вәкаләтле органга;

гаиләне дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органга;

гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органга;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында, – җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында җирле үзидарә органнарына;

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) баланы асрауга акча алуы турында, – җирле үзидарә органнарына;

гариза бирүченең гаилә составы турында – вәкаләтле органнарга;

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәте турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында – җирле үзидарә органнарына;

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында – вәкаләтле органнарга;

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса, – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органына;

вакытлыча эшкә сәләтле булмау буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук медицина учреждениеләрендә йөклелекнең башлангыч срокларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органына;

бала караган өчен айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органына;

Россия Эчке эшләр министрлыгына – пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

3.4.1, 3.4.2 пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Идарә (бүлек) белгече: гаиләнең яшәеш шартларына комиссия тикшеренүен уздыру, гаиләнең (ялгыз яши торган гражданинның) матди хәленә һәм торак-көнкүреш шартларына территориаль социаль яклау органы тарафыннан өстәмә тикшерү (комиссия тикшеренүе) уздыру датасы турында гаризада күрсәтелгән ысул (хат, смс-хәбәр, электрон почта аша) белән гариза бирүчегә язмача хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә хәбәр итү.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.5.2 пункт өстәргә:

«3.5.2. Идарә (бүлек) белгече гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү актын төзи.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедуралар тәмамлан көннән соң өч эш көне дәвамында башкарыла.»;

3.6.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүче белән берлектә 635 номерлы Нигезләмәгә 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча әңгәмә кәгазен тутыра, 635 номерлы Нигезләмәнең 2 нче; 4 нче; 6 нчы; 8 нче кушымталарында китерелгән формаларның берсе буенча Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) социаль адаптация программасын эшли;»;

3.6.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедуралар тәмамлан көннән соң биш эш көне дәвамында башкарыла.»;

3.7.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 3.4 пунктының 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында, 3.5, 3.6 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә;

гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул (хат, смс-хәбәр, электрон почта) белән гариза бирүчене социаль контрактка кул кую өчен чакыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5, 3.6 пунктларында күрсәтелгән процедуралар тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтеннән файдаланучыга хәбәр итү, дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты.»;

3.7.3 пунктның өченче, дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«635 номерлы Нигезләмәнең 3 нче; 5 нче; 7 нче; 9 нчы кушымталарында китерелгән формаларның берсе буенча гариза бирүче белән социальный контракт төзи (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләнгән очракта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 3.6.4 пунктында билгеләнгән процедуралар тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.10.1 пунктның бишенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.10.2 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.10.3 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле алтынчы бүлек өстәргә:

«6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Гариза бирүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) Идарәгә (бүлеккә) гариза җибәрү.

6.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан иркле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Гариза һәм документларны Идарәгә (бүлеккә) җибәрү.

КФҮ белгече гаризаны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарәнең (бүлекнең) һәм КФҮ үзара хезмәттәшлек итү тәртибе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән КФҮ арасында төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – КФҮ эш регламенты белән.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм документлар җибәрелә.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша КФҮгә дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында Идарә (бүлек) тарафыннан бирелгән карарда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында язма гариза тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Идарәгә (бүлеккә) техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

КФҮ белгече Идарә (бүлек) белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.»;

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән
социаль контракт нигезендә, билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының социаль яклау идарәсе (бүлеге)
башлыгына

______________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________________________

____________________________________________________________

(күрсәтергә: эшкә урнашуга; һөнәри белем алуга (өстәмә һөнәри белем алуга, стажировкага); шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, үзмәшгульлек өчен; авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән башка чараларга)

Мин,_______________________________________________________________________

(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча), түбәндәге адрес буенча яши:

_____________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

Гариза бирүченең хосусый шәхси счет номеры _____________

түбәндәгеләрне күрсәтү турында үтенәм:

миңа (минем гаиләмә) (кирәклесе астына сызарга кирәк)

гариза бирүчегә (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла) ___________________________________________________________________,

_____________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яши: ______________________________________,

_____________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________________________,

(гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме:

______________________________________________________________________________

(күрсәтергә: аз керемле гаилә буларак (аз керемле ялгыз яшәүче гражданин буларак);

_____________________________________________________________________________.

авыр тормыш хәлендә булган гаиләгә (ялгыз яшәүче гражданинга))

_______________________________________________________________рәвешендә (акчалата түләүләр, социаль хезмәтләр, натураль ярдәм)

Барлык балигъ булмаган гаилә әгъзалары социаль контракт төзүгә риза:

______________________________________________ _______________(имза)

______________________________________________ _______________(имза)

______________________________________________ _______________(имза)

______________________________________________ _______________(имза)

Дәүләт социаль ярдәменең билгеләнгән суммасын (түләүне)

түбәндәгечә гамәлгә ашырырга:

счетка күчерү юлы белән ____________________________________________

(гариза бирүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге аша

______________________________________________________________________________

(гариза бирүченең яисә аның законлы вәкиленең почта реквизитлары күрсәтелә)

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү өчен мин тапшырган мәгълүматлар тулы һәм дөрес булып тора.

Керемнәрне яшергән һәм дәүләт социаль ярдәмен алу хокукына йогынты ясарлык дөрес булмаган мәгълүматлар белән документлар тапшырган өчен җаваплылык булуы турында кисәтелде. Вәкаләтле орган вәкилләре тарафыннан мин тапшырган мәгълүматларны тикшерүгә һәм гаиләмә килүләренә каршы түгелмен.

Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, бирү (бирүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга риза:
әлеге адрес буенча язмача формада___________________________________
түбәндәге телефонга смс-хәбәр итеп ________________________________________
(телефон номеры)
әлеге электрон почта адресы буенча ___________________________________
(электрон почта адресы)

Кушымта:

1. Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында анкета ____ биттә, 1 нөсхәдә.
2. __________________________________________________________-

Дата _______________ Гариза бирүченең имзасы _________________________

Документлар кабул ителде ____________ Кабул итте ______________________(имза)»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ кушымта өстәргә:

«Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына $2^1$ кушымта

РӘВЕШЕ

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданинның) гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында анкета

| Минем һәм минем белән бер адрес буенча теркәлгән гаилә әгъзалары турында мәгълүмат: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| (Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) | Туган елы | Туганлык мөнәсәбәтләре | Төп шөгыле (эшли, эшли торган пенсионер, яше буенча пенсионер, инвалидлык буенча пенсионер, эшсез, бала карау ялында, хуҗабикә, студент, мәктәп укучысы, мәктәпкәчә яшьтәге бала) | Эшли торганнар өчен эш урыны һәм вазыйфа, укучылар өчен белем алу урыны хәзерге вакытта | 15 яшьтән өлкәнрәкләр өчен белеме |
| | | Гариза | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | бирүче | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Таблицада барлык гаилә әгъзалары, шул исәптән балигъ булмаган балалар өчен барлык мәгълүматлар күрсәтелә.

| Гариза бирүченең һәм гаилә әгъзаларының адреслы социаль ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән айга кадәрге өч айлык керемнәре турында белешмәләр: | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Тәр-тип саны | (Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) | Керем төре | Һәр ай саен керем һәм 3 ай өчен керем суммасы (сум) | | | |
| 1. | | Хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр (хезмәт хакы, эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр, акчалата керем) | | | | |
| | | Дәүләт пенсияләре | | | | |
| | | Айлык акчалата түләүләр | | | | |
| | | Социаль характердагы башка түләүләр (пособиеләр, компенсацияләр, ТКХ өчен түләү буенча ташламалар, стипендияләр һ.б.) кирәклесен ассызыкларга кирәк | | | | |
| | | Алынган алиментлар | | | | |
| | | Башка керемнәр (шәхси ярдәмче хуҗалык продукциясен сатудан, наймга торак бирүдән һ.б. – аларның төрен күрсәтергә) | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | | Хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр (хезмәт хакы, эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр, акчалата керем) | | | | |
| | | Дәүләт пенсияләре | | | | |
| | | Айлык акчалата түләүләр | | | | |
| | | Социаль характердагы башка түләүләр (пособиеләр, компенсацияләр, ТКХ өчен түләү буенча ташламалар, стипендияләр һ.б.) | | | | |
| | | Алынган алиментлар | | | | |
| | | Башка керемнәр (шәхси ярдәмче хуҗалык продукциясен сатудан, наймга торак бирүдән һ.б. – аларның төрен күрсәтергә) | | | | |
| 3. | | Хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр (хезмәт хакы, эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр, акчалата керем) | | | | |
| | | Дәүләт пенсияләре | | | | |
| | | Айлык акчалата түләүләр | | | | |
| | | Социаль характердагы башка түләүләр (пособиеләр, компенсацияләр, ТКХ өчен түләү буенча ташламалар, стипендияләр һ.б.) | | | | |
| | | Алынган алиментлар | | | | |
| | | Башка керемнәр (шәхси ярдәмче хуҗалык продукциясен сатудан, наймга торак бирүдән һ.б. – аларның төрен күрсәтергә) | | | | |
| 4. | | Хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр (хезмәт хакы, эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр, акчалата керем) | | | | |
| | | Дәүләт пенсияләре | | | | |
| | | Айлык акчалата түләүләр | | | | |
| | | Социаль характердагы башка түләүләр (пособиеләр, компенсацияләр, ТКХ өчен түләү буенча ташламалар, стипендияләр һ.б.) | | | | |
| | | Алынган алиментлар | | | | |
| | | Башка керемнәр (шәхси ярдәмче хуҗалык продукциясен сатудан, наймга торак бирүдән һ.б. – аларның төрен күрсәтергә) | | | | |

*Мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 3 айлык чорда ______________________________

файдасына ________ №_________ башкару кәгазе буенча тотып калынган, минем тарафтан

түләнгән ____________ сум күләмендәге алиментларны минем гамләнең гомуми кереме

суммасыннан төшереп калдыруыгыз турында үтенәм

Гаиләнең торак-көнкүреш шартлары:
торак мәйданы: __________ кв. м.; милек формасы: _________________________;
бүлмәләр саны _______.

Йортның сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б., нормаль хәлдә, тузган, аварияле – *кирәклесен ассызыкларга*)

Торакның төзекләндерелеше (суүткәргеч, канализация, җылылык, газ, ванна, лифт, телефон һ.б. – *кирәклесен ассызыкларга*)

Милек хокукында минеке һәм гаилә әгъзаларымныкы булган күчемсез мөлкәт һәм башка милек турында, җир кишәрлегенә, крестьян хуҗалыгына, шәхси ярдәмче хуҗалыкка ия булу турында белешмәләр:

| Мөлкәт төре | Урнашкан адресы (автомобиль өчен: маркасы һәм эксплуатацияләү срогы) | Кемгә карый |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Сәламәтлек торышы (яхшы, начар, бик начар, инвалидлык булу):
Гариза бирүче____________________________
Ир (хатын)_____________________
Балалар________________________________
Бергә яши торган башка туганнар_________________

Авыр тормыш хәленнән чыгу буенча күз алдында тотылган эшчәнлек юнәлешләре (гариза бирүче фикере) ________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Социаль контрактны үтәү шартларына йогынты ясый торган шартлар турында алар башланганнан соң ике атна эчендә хәбәр итәргә сүз бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| __________ (дата) | ______________________ фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) | __________ (имза) |

Айлык пособие исәпләү:

| Гаилә кеременең гомуми суммасы 3 ай эчендә | Гаилә кеременең гомуми суммасы 1 ай эчендә | Анкетаны тутыру аенда гаиләнең яшәү минимумы | Керемнең яшәү минимумыннан артып китүе | Социаль контракт төзү мөмкинлеге (әйе яисә юк) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Анкетаны кабул итү турында билге _______________________________________

* Алиментлар түләү очрагында тутырыла. Алиментлар түләнмәгән очракта, сызык куела».